ҖОМГА
26
МАРТ
1943 ел.
№ 67 (6789)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

ТРАКТОРЧЫ

Партиябез һәм хөкүмәтебез 1943 нче елда барлык авыл хуҗалыгы культураларының уңышын тагын да югарырак күтәрүне ил алдында торган иң әһәмиятле бурычларның берсе итеп билгеләделәр. «1943 нче елга авыл хуҗалыгын үстерү буенча дәүләт планы турында» ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карары бу гаять җаваплы бурычны үтәү өчен көрәштә сугышчан программа булып тора. Бу программаны тормышка ашыру быел фронтны һәм илебезне туклану әйберләре белән, промышленностьны чимал белән һичшиксез тагын да муллрак тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

1943 нче елга авыл хуҗалыгы алдына куелган бурычларны уңышлы итеп башкарып чыгуда җанлы тарту көчләре белән берлектә механик тарту көчләреннән дөрес һәм тулысынча файдалану хәлиткеч рольне уйнаячак. Шуңа күрә дә хәзер, язгы чәчү алдыннан атларны тәрбия итүгә, мөгезле эре терлекне җигүле эшкә күнектерүгә, тракторларга, аларга тагылма барлык катлаулы һәм гади машиналарга ремонт ясауны тизрәк төгәлләүгә җитди игътибар бирелергә тиеш. Быел һәрбер авыл хуҗалыгы машинасы сәгать механизмы кебек төгәл эшләрлек булсын.

Ләкин машина никадәр генә төгәл һәм төзек булса да, кеше ярдәменнән башка эшли алмый ул. Сүз тракторчы турында, аңа теоретик белем бирү өстенә аны тракторда эшләүгә язгы чәчүгә кадәр ныклап күнектерү турында бара. Чөнки бездә быел тракторда эшләү буенча зур практикалы кадрлар белән бер рәттән тракторда бер генә сезон эшләгән, яки әле менә хәзер генә курс бетергән тракторчылар да шактый күп булачак. Тракторчылар әзерләү курсларын быел бетереп чыгучылар өчен кыр эшләре башланганчыга кадәр практик күнегүләр оештыруга аеруча әһәмият бирергә кирәк. Алар кыр эшләре башлануның беренче көненнән үк эшкә тулы әзерлек һәм ышаныч белән керешерлек булсыннар. Үткән елгы кимчелекләр—тракторда кечкенә генә ватылу килеп чыккан саен аптырашта калып, трактор янында көннәр буена бушка вакыт үткәрү фактлары быел һич тә кабатланмаска тиеш. Шөгер МТС ында үткән елны нәкъ әнә шулай булган иде. Яхшы әзерлекле тракторчы кадрлар җитәрлек булмау нәтиҗәсендә, бу МТС та бик күп тракторлар кызу эш вакытында бик еш туктап тордылар. Нәтиҗәдә, бу МТС тракторлар эше буенча планны үтәмәде, байтак кына ягулыкны артык тотты. Ә менә инде Янил МТС ы үткән елны яшь тракторчыларны алдан ук, курста укыганда ук практик белем белән коралландыруга әһәмият бирү аркасында зур уңышларга иреште. Үткән елны Янил МТС ы янында тракторчылар әзерләү буенча булган курсны бетереп чыгучылардан Бикә иптәш Гыйззәтуллина үз тракторында сезон буенча һичбер авариясез эшләп чыкты һәм «Советлар Союзының иң яхшы тракторчысы» исемен алуга иреште. Шул ук МТС ның үткән ел тракторда беренче ел эшләгән тракторчыларыннан Мөстәкыймова һәм Гарәпшина иптәшләр үзләренә бирелгән еллык заданиене 170—180 процентка үтәп, алдынгы МТС ның алдынгылары исемен яулап алдылар. Ленин орденлы Актаныш МТС ында һәм Кызыл юл МТС ында да әнә шулай бөтен союз күләмендә дан казанган тракторчылар бар. Быел барлык тракторчыларның да, шул исәптән тракторда беренче ел эшләүчеләрнең дә әнә шулай яхшы эшләүләренә ирешү өчен көрәшне хәзердән үк оештырырга кирәк. Бу эштә өлкән тракторчылар өстенә зур җаваплылык йөкләнә. Механизатор яшь кадрларны өзлексез кайгыртучанлык белән чолгап алырга, аларга трактор техникасын яхшы итеп үзләштерүдә булышлык итәргә кирәк.

Хәзерге көндә Советлар Союзының мактаулы трактор бригадасы бригадиры Дарья иптәш Гармаш (Рязань өлкәсе, Рыбново МТС ы) һәм аның бригадасы членнары чакыруы буенча тракторчылар арасында социалистик ярыш көннән-көн җәелә. Бригадирлар һәм тракторчылар, быел тагын да яхшырак эшләргә йөкләмәләр алып, үзара социалистик ярыш договорлары төзиләр. Тәҗрибәләре аз булган яшь тракторчыларга практик эштә көн саен булышлык күрсәтү ярыш договорында төп пунктларның берсе булырга тиеш. Яз якынлаша. Ямле сабан өсте килеп җитә. Язгы чәчүнең быел шактый кыен шартларда үтәчәген бер генә минутка да истән чыгармаска, тракторчылар арасында социалистик ярышны һәм масса - аңлату эшләрен киң җәелдереп, механик тарту көчләреннән тулысынча файдалануны тәэмин итәргә кирәк.

ВКП(б) ның ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫННАН, ТАССР СОВНАРКОМЫННАН

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә һәм Казан шәһәр комитетлары, ТАССР Халык Комиссарлары Советы Татарстан АССР Верховный Советы депутаты, ВКП(б) члены иптәш Шаһи Хатип улы Садыйковның үлүе турында тирән кайгы белән белдерәләр.

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә һәм Казан шәһәр комитетлары,
ТАССР Совнаркомы.

ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫННАН

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Татарстан АССР Верховный Советы депутаты иптәш Шаһи Хатип улы Садыйковның үлүе турында тирән кайгы белән белдерә.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы.

Москва, Кремль, иптәш Иосиф Виссарионович СТАЛИНГА

Кадерле Иосиф Виссарионович!

Минем «Емельян Пугачев» операма югары бәя биргән өчен Совет хөкүмәтенә чын күңелдән рәхмәт белдерәм. Миңа билгеләнгән 100.000 сум күләмендәге премияне самолетлар төзелешенә кертәм.

Төзелгән самолетка рус халкының азатлыгы һәм бәхете өчен көрәшкән Емельян Пугачев исемен бирүне һәм бу самолетны Төньяк-Көнбатыш фронт командованиесе карамагына тапшыруны үтенәм.

Сезгә, кадерле Иосиф Виссарионович, озак еллар буенча сәламәтлек һәм тазалык телим.

Композитор Мариан Викторович КОВАЛЬ.

КОМПОЗИТОР ИПТӘШ МАРИАН ВИКТОРОВИЧ КОВАЛЬГА

Кызыл Армиянең һава көчләре турында Сезнең кайгыртучанлык күрсәтүегез өчен, Мариан Викторович, минем сәламымны һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен кабул итегез.

Сезнең теләгегез үтәлер.

И. СТАЛИН.

Москва, Кремль, иптәш Сталинга

Кадерле Иосиф Виссарионович!

Хөкүмәтнең югары бүләге—Сезнең исемдәге премия белән канатланган хәлдә, киләчәктә дә үземнең барлык көчемне, белемемне һәм барлык художник-скульпторлык сәләтемне героик халкыбызның, аның данлыклы улларының һәм кызларының батырлыкларын мәңгеләштерүгә куярга Сезгә вәгъдә бирәм. Кешелек дөньясының яхшы киләчәге өчен тормышын да кызганмыйча Сезнең исемегезне әйтеп көрәшүчеләрнең якты образлары алдагы буыннарга барып җитсен. Баш Командованиε фондына премия суммасын—100.000 сум акча кертеп, Сезнең даһи җитәкчелегегездәге данлыклы Кызыл Армиябезнең явыз дошманны тар-мар итү һәм аны туган җиребездән куу сәгате якын икәнлеккә нык ышанам.

Скульптор Матвей МАНИЗЕР.

ЯРОСЛАВЛЬ

СКУЛЬПТОР ИПТӘШ МАТВЕЙ ГЕНРИХОВИЧ МАНИЗЕРГА

Кызыл Армия турында Сезнең кайгыртучанлык күрсәтүегез өчен, Матвей Генрихович, минем сәламымны һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен кабул итегез.

И. СТАЛИН.

Фән өлкәсендә 1942 нче елда булган күренекле хезмәтләр өчен Сталин премияләре бирү турында

Физика-математика, техника, химия, геология—география, биология, авыл хуҗалыгы, медицина фәннәре, хәрби фән һәм башка фәннәр өлкәсендә 1942 нче елны булган күренекле хезмәтләр өчен ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы зур бер группа работникларга Сталин премияләре бирергә карар бирде.

Физика-математика фәннәре буенча 200.000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премияләр түбәндәге кешеләргә билгеләнде:

СССР Фәннәр академиясенең член-корреспонденты Москваның М. В. Ломоносов исемендәге, Ленин орденлы дәүләт университеты профессоры П. С. Александровка—математика өлкәсендәге фәнни хезмәтләре өчен; СССР Фәннәр академиясенең действительный члены, СССР Фәннәр академиясенең физика проблемалары институты директоры П. Л. Капицага—сыек гелийның үтә агылучанлыгы күренешләрен ачкан һәм тикшергән өчен (бу эшнең нәтиҗәләре 1941 нче елның ахырында игълан ителделәр).

Техника фәннәре буенча 200.000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премияләр СССР Фәннәр академиясенең член—корреспонденты, СССР Фәннәр академиясенең теоретик геофизика институтының фәнни сотрудникы, Москваның Губкин исемендәге нефть институты профессоры Л. С. Лейбензонга—сыгылмалылык һәм нефть промыслосы механикасы өлкәсендәге тикшеренүләре өчен.

Химия фәннәре буенча 200:000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премияләр СССР Фәннәр академиясенең член-корреспонденты, СССР Фәннәр академиясенең органик химия институты директоры А. Н. Несмеяновка—металл-органик кушылмалар өлкәсендә 1941 һәм 1942 нче елларда күп кенә мәкаләләрдә үзләренең нәтиҗәләре игълан ителгән тикшеренүләре өчен.

Авыл хуҗалыгы фәннәре өлкәсендә 200.000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премияләр түбәндәге кешеләргә билгеләнде.

СССР Фәннәр академиясенең действительный члены Т. Д. Лысенкога, В. И. Ленин исемендәге Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы фәннәре академиясенең действительный члены В. П. Мосоловка, шул ук академиянең фәнни сотрудниклары И. Д. Колесникка һәм А. К. Зубаревка, шул ук академиянең Казахстан филиалы сотрудникы Ф. С. Солодовниковка, Тимирязов исемендәге Москва авыл хуҗалыгы академиясе укытучысы А. Ф. Голиковка, бәрәңге хуҗалыгы институты директоры В. В. Арнаутовка, СССР Фәннәр академиясенең генетика институты сотрудникы И. Е. Глущенкога—бәрәңге үсентеләре утырту методын фәнни яктан эшләгән өчен һәм бу методны авыл хуҗалыгына үткәргән өчен.

Медицина фәннәре буенча 200 000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премияләр түбәндәге кешеләргә билгеләнде:

Медицина хезмәтләре генерал-лейтенанты, Кызыл Армиянең С. М. Киров исемендәге хәрби - медицина академиясе профессоры В. Н. Шевкуненкога, шул ук академиянең профессорлары А. Н. Максименковка һәм А. С. Вишневскийга—1942 нче елны тәмам булган «Нервлар һәм кан тамырлары системалары атласы» дигән фәнни хезмәт өчен.

Хәрби фәннәр буенча 100.000 сум күләмендәге икенче дәрәҗәдәге премияләр түбәндәге кешеләргә билгеләнде:

Ворошилов исемендәге хәрби-диңгез академиясе профессоры, вице-адмирал Л. Г. Гончаровка—1942 нче елны тәмам булган «Корабль артиллериясеннән сугышта файдалану» дигән әсәре һәм башка хезмәтләре өчен.

Тарих-тел фәннәре буенча 200.000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премияләр түбәндәге кешеләргә билгеләнде:

СССР Фәннәр академиясенең член-корреспонденты И. И. Минцка, профессор Г. Ф. Александровка, профессор П. Н. Поспеловка, СССР Фәннәр академиясенең действительный члены Е. М. Ярославскийга, Ломоносов исемендәге Москва дәүләт университеты профессоры Э. Б. Генкинга, шул ук университетның доценты Е. Н. Городецкийга, шул ук университетның профессорлары И. М. Разгонга һәм И. П. Товстухага—«СССР да гражданнар сугышы тарихы» дигән фәнни хезмәтнең 1942 нче елны басылып чыккан II нче томы өчен; СССР Фәннәр академиясенең действительный члены Е. В. Тарлега—1942 нче елны басылып чыккан «Кырым сугышы» дигән фәнни хезмәте өчен.

Философия фәннәре буенча 200.000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премияләр түбәндәге кешеләргә билгеләнде,

Профессор Г. Ф. Александровка, СССР Фәннәр академиясенең философия институты профессоры Б. Э. Быховскийга, СССР Фәннәр академиясенең действительный члены М. Б. Митинга, СССР Фәннәр Академиясенең член-корреспонденты П. Ф. Юдинга, СССР Фәннәр академиясенең философия институты директоры О. В. Трахтенбергка, Москва дәүләт университеты профессоры В. Ф. Асмуска, М. А. Дынникка, М. М. Григорьян—I томы 1940 нчы елны, II нче томы 1941 нче елны һәм III нче томы 1942 нче елны басылып чыккан «Философия тарихы» дигән фәнни хезмәт өчен.

Фән һәм техника өлкәсендә күп еллык күренекле хезмәтләр өчен академиклардан М. И. Авербахка, А. А. Байковка, Б. Е. Веденеевка, В. И. Вернадскийга, С. М. Джанашиага, Б. Д. Грековка, И. И. Мещаниновка, В. Ф. Миткевичка, С. С. Наметкинга, А. Е. Порай-Кошицка, М. П. Чижевскийга һәм К. И. Шенфергка 200.000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премияләр билгеләнде.

100.000 сум күләмендәге икенче дәрәҗәдәге премияләр академиклардан А. Е. Арбузовка, А. А. Борисякка Н. Ф. Гамалеяга, Н. Т. Гудцовка, А. Н. Заварицкийга, В. Н. Образцовка, А. М. Терпигоревка, Е. А. Чудаковка, Е. Ф. Лискунга, П. Н. Константиновка, И. В. Якушкинга, профессор В. П. Ветчинкинга һәм башкаларга—барлыгы 35 кешегә билгеләнде.

(ТАСС).

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. РӘСЕМДӘ: лейтенант А. Афонин командалыгындагы батарея орудиесе һөҗүм итеп алга баручы пехотага ярдәм итә. ТАСС фотохроникасы.

1942 нче елда булган күренекле уйлап табулар һәм производство эше методларын яхшыртулар өчен Сталин премияләре билгеләү

1942 нче елда булган күренекле уйлап табулар һәм производство эше методларын тамырыннан яхшыртулар өчен ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы зур бер группа уйлап табучыларга, промышленность һәм авыл хуҗалыгы работникларына Сталин премияләрен бирергә карар бирде.

150.000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премияләр түбәндәге кешеләргә билгеләнде:

Социалистик хезмәт геройлары С. В. Ильюшинга, Н. Н. Поликарповка һәм А. С. Яковлевка, Фәннәр академиясенең член-корреспонденты А. Н. Туполевка һәм конструкторлардан П. О. Сухойга һәм С. А. Лавочкинга — сугыш самолетлары конструкцияләрен модификацияләгән, яхшырткан һәм яңа үрнәкләрен тудырган өчен; Социалистик Хезмәт Герое А. Д. Швецовка һәм А. Д. Чаромскийга—авиация моторының һәм двигателенең яңа үрнәкләрен төзегән өчен; Социалистик Хезмәт Геройлары В. В. Грабинга, И. И. Ивановка, конструкторлардан Д. И. Шефферга, П. М. Назаровка, К. К. Реннега, М. М. Розенбергка, В. Д. Мещаниновка, Социалистик Хезмәт Герое Ж. Я. Котинга, С. Н. Махонинга, Л. С. Трояновка, Ф. Ф. Петровка, С. П. Горенкога һәм башкаларга—артиллерия коралларының яңа үрнәкләрен эшләгән өчен; Б. М. Малининга, Б. Ф. Крицкинга һәм башкаларга—сугыш корабленең яңа тибын тудырган өчен; Н. А. Блохинга, А. Г. Шереметьевка һәм башкаларга—хәрби промышленностьта корыч коюның яңа технологиясен эшләгән һәм производствога керткән өчен;

Беренче премия барлыгы 120 кешегә билгеләнде.

100.000 сум күләмендәге икенче дәрәҗәдәге премияләр түбәндәге кешеләргә билгеләнде:

А. Э. Автомьянга, Н. Н. Остряковка һәм башкаларга — корабль артиллериясенең ату эффектын арттырган өчен; В. С. Мелик-Пашаевка, Е. Я. Дмитриевка һәм башкаларга—нефть чыга торган яңа урыннар эзләп тапкан һәм алардан файдалануны юлга салган өчен; С. С. Гирголавка, Т. Я. Арьевка, һәм В. Н. Шейниска—өшегән урыннарны дәвалауны тизләтә торган яңа методлар эшләгән өчен; Социалистик хезмәт геройлары В. Я. Климовка һәм А. А. Микулинга—авиация моторын яхшырткан өчен; «Красный пролетарий» заводы токаре С. Ф. Смирновка—металлны механик эшкәртүдә югары хезмәт житештерүчәнлеген тәэмин итә торган җайланмалар эшләгән һәм куллаган өчен; Кара металлургия халык комиссариатының Высокогорск руднигы эшчесе И. П. Завертайлога—тау рудасы промышленностенда күп забойлы тизләтелгән бораулау методын яхшыртып, хезмәт житештерүчәнлеген күтәрүне һәм руда чыгаруны шактый арттыруны тәэмин иткән өчен; 3 нче номерлы заводның баш конструкторы Л. М. Кошкинга — күп эшләр башкара торган югары житештерүчәнлекле яңа станоклар төзегән өчен; нәселле терлекләр совхозы «Караваево»ның өлкән зоотехнигы С. И. Штейманга—продукт бирүләре ягыннан рекорд бирерлек яңа сөт терлекләре булдырган өчен.

Икенче премия белән барлыгы 138 кеше бүләкләнде.

50.000 сум күләмендәге өченче дәрәҗәдәге премияләр түбәндәге кешеләргә билгеләнде:

Электр промышленносте халык комиссары урынбасары Г. В. Алексеенкога, 715 нче номерлы заводның өлкән мастеры И. М. Гульдинга һәм башкаларга—сугыш припаслары детальләре житештерүдә тагын да күбрәк нәтиҗә бирә торган яңа технология эшләгән өчен һәм аны тормышка үткәргән өчен; 10 нчы номерлы фәнни-тикшеренү институтының өлкән инженеры А. Н. Морозовка һәм башкаларга—зенит артиллериясе утын идарә итүдә яңа прибор төзегән өчен; Уралмашзаводның корыч коючысы Ибраһим Вәлиевка һәм Сталин исемендәге Кузнецк металлургия комбинатының корыч коючысы А. Я. Чалковка—сыйфатлы корычлар койганда югары сыйфат күрсәткечләренә ирешкән өчен, Новосибирск өлкәсе, Мариинск районы, «Красный Перекоп» колхозының звено житәкчесе А. К. Юткинага һәм аның 9 кешедән торган бөтен звеносына — яхшыртылган агрономия методларын берничә еллар рәттән үткәреп килгән өчен һәм 1942 нче елны бәрәңгедән рекорд уңыш—гектарыннан 1.330 центнер алган өчен.

Өченче премияләр галимнәрдән, уйлап табучылардан, промышленность һәм авыл хуҗалыгы работникларыннан барлыгы 188 кешегә бирергә билгеләнде. (ТАСС).

Совет Информбюросыннан

24 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

24 нче мартта безнең һөҗүм итеп баручы гаскәрләребез район үзәге һәм тимер юл станциясе Абинскаяны алдылар (Новороссийскидан төньяк-көнбатыштарак).

Башка фронтларда безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

***

23 нче мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 2 сугыш припаслары складын шартлаттылар, 10 артиллерия һәм миномет батареясының утын бастырдылар.

***

Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр, дошманның каты каршылык күрсәтүен җиңеп, халык яши торган берничә пунктны алдылар. Н-че берләшмә частьлары су чиге аркылы үтеп чыктылар һәм дошманның ныгытылган позицияләрен кулга төшерделәр. Сугыш кырында дошманның 200 гә якын үле гәүдәләре калды. 4 орудие, 17 пулемет, күп кенә винтовкалар һәм патроннар кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр немецларны тимер юл станциясе Дорогубждан 4 километр төньяктарак булган Сафоново авылыннан бәреп чыгардылар. Дошман бик күп кешеләрен һәм техникасын югалтты.

***

Духовщинадан төньякта Н-че берләшмә частьлары һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган 7 пунктны алдылар. Бер участокта безнең бер частебыз бер ротага якын немец пехотасын кырып ташлады. Трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында 5 танк һәм 14 орудие бар. Чаңгычы гвардеецлар подразделениесе, омтылышлы удар ясап, немецларны Җутуны авылыннан бәреп чыгардылар. Гвардеецлар авыл халкыннан 60 тан артык кешене һәлак булудан коткарып калдылар. Немецлар хатын-кызларны, картларны һәм балаларны бер йортның подвалына куып керткәннәр һәм йортны яндырганнар. Авылга бәреп кергән совет сугышчылары янгынны сүндерделәр һәм һәлакәткә дучар ителгән совет кешеләрен коткардылар.

* * *

Белгород районында немецларның бер батальон пехотасы, 12 танк ярдәме белән, безнең позицияләргә атака ясарга маташып карады. Н-че часть сугышчылары 150 гитлерчыны кырып ташладылар. дошманның 3 танкысын сафтан чыгардылар һәм немецларны ашыгыч рәвештә чигенергә мәҗбүр иттеләр. Икенче бер участокта совет артиллериясенең уты белән дошманның 2 арилле рия батареясы юк ителде һәм җыелып тора торган пехотасы таркатылды.

***

Чугуевтан төньяктарак безнең гаскәрләр Төньяк Донец елгасына чыгарга маташкан дошман пехотасына һәм танкларына каршы сугышлар алып бардылар. Н-че часть сугышчылары гитлерчыларның барлык атакаларын кире кайтардылар. Немецларның 9 танкысы, 13 автомашинасы һәм 100 дән артык солдат һәм офицерлары юк ителде.

***

Орел өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды шушы көннәрдә немецларның станция янындагы поселокка урнашкан бер гарнизонына һөҗүм иткән. Партизаннар 96 гитлерчыны кырып ташлаганнар, стрелкаларны һәм тимер юлны шартлатканнар. Бу участокта поездлар йөреше тукталган. Икенче бер отрядның бер группа партизаннары 40 ка якын гитлерчыны юк иткәннәр һәм немецларның бер азык складын, 800 метр телефон кабелен, 4 пулеметын, 14 атын һәм төрле сугыш милекләрен кулга төшергәннәр.

***

Немецларның 329 нчы пехота дивизиясенең 552 нче полкыннан Демянск районында плен алынган обер-ефрейтор Вильһельм Фраке болай диде: «Үткән елны көз көне безгә, Залучье авылына, генерал-майор Вернер килде. Ул үзенең речендә хәзер немецларның төп кораллы көчләренең көньякта мәшгуль икәнлекләрен, ә безнең монда оборонада торуыбызны әйтте. Аның әйтүенчә, Сталинград белән эш беткәч үк без һөҗүмгә күчәргә тиеш идек. Шуннан соң немец гаскәрләре Демянскидан русларга кискен удар ясарга һәм сугышны тәмам итәргә тиешләр иде. Февраль аенда, русларның удары астында качкан чакта, без генералның бу сүзләрен ләгънәтләр укып искә алдык. Безне Сталинград янында немецларның 6 нчы армиясе очраган язмыштан бары тик аякларыбыз гына коткарып калды. Бу сугышларда 552 нче полк үзенең кешеләр составының 70 проценттан артыгын югалтты. Безнең ротада бары 22 кеше калды. Соңгы сугышта, руслар якынлашып килгәндә, лейтенант һәм фельдфебель качтылар. Без, барыбыз 20 кеше, окопларда калдык һәм плен бирелдек».

25 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

25 нче мартта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

***

24 нче мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән кимендә 50 автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, бер сугыш припаслары складын шартлаттылар, 8 кыр һәм зенит артиллериясе батареясының утын бастырдылар.

***

Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр халык яши торган берничә пунктны алдылар. Н-че часть сугышчылары дошманның көчле итеп ныгытылган бер терәк пунктын әйләнеп үтеп, немецлар гарнизонына тылдан атака ясадылар һәм өз гына сугышканнан соң бу пунктны алдылар. Бер сугыш припаслары склады, 3 орудие, күп кенә винтовкалар, гранаталар һәм патроннар кулга төшерелде. Пленныйлар алынды.

***

Белгород районында Н-че часть подразделениеләре немецларның су чиге аркылы үтәргә маташкан бер рота автоматчикларын тар-мар иттеләр. Сугыш кырында дошманның 100 дән артык үле гәүдәләре калды. Безнең артиллериянең уты белән немецларның 3 танкысы, танкка каршы ата торган 5 орудиесе сафтан чыгарылды, бер батальонга якын пехотасы таркатылды һәм бер өлеше юк ителде.

***

Чугуевтан төньякта безнең частьлар оборона сугышлары алып бардылар. Иртә белән немецларның бер полк пехотасы, 20 танк ярдәме белән, бер биеклеккә атака ясаган иде. Бу атакага артиллерия һәм авыр минометлар уты булышлык иттеләр. Безнең сугышчылар дошманның басымын кире кайтардылар һәм үзләренең позицияләрен саклап калдылар. Немецларның 7 танкысы һәм 5 самоход пушкасы зарарланды һәм яндырылды. Шулай ук икенче бер участокта да немецларның атакасы уңышсыз чыкты. Гитлерчылар, совет артиллериясенең бик көчле утына очрап, сугыш кырында 200 дән артык үле гәүдәләрен калдырып, ашыгыч рәвештә чигенделәр.

* * *

Харьков өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды халык яши торган бер зур пунктка һөҗүм иткән һәм андагы немецлар гарнизонын туздырган. 80 гитлерчы үтерелгән. Немецлар тарафыннан атарга хөкем ителгән 20 совет гражданы азат ителгән. Шуның өстенә партизаннар дошманның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. Җимерек вагоннар астында калып, берничә дистә немец-фашист басып алучылар һәлак булган.

***

«Адольф Гитлер» исемле СС дивизиясенең беренче полкының 11 нче ротасыннан плен алынган солдат Август Зуэр болай диде: «Безнең дивизия Франциядә иде. Үткән елның ноябрендә дивизияне Төньяк Африкага җибәрергә хәзерләнә башладылар. Бөтен личный составка медицина тикшерүе үткәрделәр. Африкада хезмәт итү өчен яраксыз дип табылган кешеләр барысы да башка частьларга күчереләчәк иде. Ләкин көтмәгәндә генә дивизияне Россиягә җибәрү турында приказ алынды. Январь уртасында дивизиянең подразделениеләрен көнчыгыш фронтка җибәрә башладылар. Юлда барганда солдатлар немец гаскәрләренең Россиядә авыр җиңелүләргә дучар булганлыкларын һәм Сталинград янында фельдмаршал Паулюс армиясенең һәлак булганлыгын ишеттеләр. Солдатлар болай диделәр: «Әгәр дә немец гаскәрләре тагын бер кат шундый җиңелүгә очрасалар, ул чагында Германия гаять күп корбаннар исәбенә берничә ел буена алып килгән бөтен нәрсәсен югалтачак». Күп офицерларның һәм солдатларның фикеренчә, Франциядән сугышка яраклы иң яхшы дивизияләрне күчерү гаять зур куркынычларга бәйләнгән».

***

Түбәндә немец-фашист кабахәтләренең совет хәрби пленныйларына карата эшләгән ерткычлыклары турындагы акт игълан ителә, «Курск өлкәсенең немецлардан азат ителгән Зорино авылында 32 совет сугышчысының үле гәүдәләре табылды. Аларның сугыш кырында яраланганлыклары, плен алынганлыклары һәм гитлерчылар тарафыннан ерткыч төстә газаплангачлыклары беленде. Ике кызылармеецның күзләрен тишеп чыгарганнар, берсенең йөзен яньчеп бетергәннәр. Өч үле гәүдә яндырылган. Бандитлар 3 нче ранг хәрби врач Заливакинаның һәм санитарка Мария Федотованың башларын яньчегәннәр». Актка өлкән лейтенант Толмасов, кызылармеец Суханов, колхозчылар Фетисов һәм Мелиховалар кул куйганнар.

***

Загреб-Сплит тимер юл районында хәрәкәт итүче Югославия партизаннары немец сакчыларны таркатканнар һәм бу юлда иң зур виадук булган Бендер виадугын шартлатканнар. Поездларны яңадан нормаль төстә йөртә башлау өчен берничә айлар кирәк булачак. Невеса кырында партизаннар оккупантларның бер колоннасын тар-мар иткәннәр. 200 дән артык дошман солдатлары һәм офицерлары юк ителгән. 7 авыр миномет, 11 пулемет һәм сугыш йөкләре төялгән 100 повозка кулга төшерелгән.

АЗАТ ИТЕЛГӘН РАЙОННАРГА

Казан шәһәренең Сталин районындагы 2 нче номерлы мәктәп укучылары азат ителгән районнардагы мәктәпләр һәм көтепханәләр өчен бик күп әдәби китаплар, дәреслекләр һәм уку әсбаплары җыйдылар. Рәсемдә: уныпчы класс укучыларыннан (сулдан уңга) Г. Тарасова, К. Фалина һәм А. Курмашева укучы З. И. Михеевага китаплар тапшыралар.

К. Тахтеев фотосы.

СТАЛИНГРАД ӨЛКӘСЕ ЯҢАДАН ЧӘЧӘК АТАР

(Сталинград өлкәсе, ВКП(б) ның Городищенский райкомы секретаре иптәш АНТОНОВ белән беседа).

Сталинград өлкәсенең Городищенский районын немец талаучылары оккупацияләгәнгә кадәр, анда 29 колхоз, 2 МТС, итчелек-сөтчелек совхозы, кырчылык һәм терлекчелек буенча ике тәҗрибә станциясе, 6 тимер юл станциясе, 2 больница, 4 урта, 11 тулы булмаган урта, 19 башлангыч мәктәп, 20 уку өе, 11 клуб бар иде. Халык яши торган 42 пунктта барлыгы 30 меннән артык халык яши иде.

Районда 43 мең гектардан артык чәчү мәйданы, колхоз фермаларында 6.000 баш эре терлек исәпләнә иде, һәм ул һәр елны дәүләткә меңнәрчә тонна ашлык, яшелчә, ит һәм башка төрле авыл хуҗалыгы продуктлары тапшырып килде. Районның колхозлары 1942 нче елда гына да дәүләткә 110.000 центнер ашлык, 600.000 центнер яшелчә тапшырдылар.

Гөрләп чәчәк аткан Городищенский районы. 1942 нче елның август аенда немец бандитлары армиясе тарафыннан оккупацияләнеп, талануга, мыскыллануга дучар ителде. Гитлерчы бандитлар, үзләре хуҗа булып торган аз гына вакыт эчендә районны тәмам бөлгенлеккә төшергәннәр. Алар мәктәпләрне, больницаларны, колхоз фермаларын һәм авылларны яндырганнар. Самофаловка, Котлубан, Кече һәм Зур Россошка, Новая Надежда авылларын, Плантатор, Ягодная, Цибинка, Дубинино хуторларын, анда калган халыклары белән берлектә көлгә әверелдергәннәр. Колхозлардагы бер генә төзелеш тә, бер генә инвентарь да исән калдырылмаган.

Гитлерчы талаучылар колхозчыларны талаганнар, аларның барлык азыкларын, терлекләрен һәм йорт әйберләрен талап алганнар. Алар Орловка авылында урамда йөрүче 8 яшьлек Володя Авдеевның аягыннан киез итеген, өстеннән пальтосын салдырып алганнар. Володя урамда өшеп үлгән. Городище авылында Свиридов, Алеев, Иванов дигән 3 яшь үсмерне партизанлыкта гаепләп атып үтергәннәр. Песковатка авылында 4 кыз немецларга эшләүдән баш тарткан өчен ерткычларча җәзаланып үтерелгән. 5 ай эчендә районда барлыгы 700 дән артык кеше ачтан үлүгә дучар ителгән.

Мондый фактларны тагын да бик күп китерергә мөмкин.

Бөек полководец иптәш Сталин җитәкчелегендәге героик Кызыл Армия 1943 нче елның 27 нче январенда районны фашистлар коллыгыннан азат итте. Немец фашистларның сайланып алынган 6 нчы армиясе Сталинград янында үзенә кабер тапты. Кеше үтерүче ерткычларга, гитлерчы талаучылар армиясенә Городищенский районы колхозчыларыннан мәңгелек ләгънәт булсын.

Хәзер Городищенский районы колхозчылары иркен сулыш белән сулыйлар. Район тормышка кайтарыла. Җитәкче работникларның күпчелеге урыннарына кайттылар һәм эшкә керештеләр. Район немецларның пычракларыннан чистартыла һәм тәртипкә китерелә. 4 мәктәптә укулар башланды. 3 урында ашханә ачылды. Язгы чәчүгә әзерлек эшләрен башлап җибәрдек. Район үзәгендә ачылган курсларда 200 кеше тракторчылар, чәчүчеләр, бригадирлар булырга әзерләнәләр. «VIII Съезд Советов», «Большевик», Димитров исемендәге колхозларда тимерчелек мастерскойлары эшкә керештеләр. Балалар бакчаларын һәм ясленәрне ачып җибәрү өчен әзерлек эшләре алып барабыз.

Сталинград өлкәсен һәм аның районнарын аякка бастыру мәсьәләсе белән барлык совет халкы шөгыльләнә. Күп кенә өлкәләр, аерым районнарны шефка алып, ул районнарны аякка бастыруда практик булышлык күрсәтәләр. Алар чәчүлек орлыклары, терлекләр, төзү материаллары, йорт әйберләре һәм башка нәрсәләр җибәрәләр. Орденлы Татарстан хезмәт ияләре дә бу өлкәдә читтә калмыйлар.

Без, совет җәмәгатьчелегенең ярдәме белән өлкәдә халык хуҗалыгын тизлек белән аякка бастырырбыз. Даһи полководец иптәш Сталин исемен йөртә торган Сталинград өлкәсе яңадан чәчәк атар.

16 ВАГОН ӘЙБЕР ӘЗЕРЛӘНӘ

Казанның Свердлов районы хезмәт ияләре Сталинградны аякка бастыру өчен төзү материаллары, акча һәм башка әйберләр җыюны оештырдылар. 7 предприятиедә генә дә 16 вагон төрле материаллар тупланды. Алар арасында 12 вагон бүрәнә, бер вагон такта, 3 вагон төрле металл әйберләр; шул исәптән 12 станок, 1.000 гә якын инструмент, 200 метр корыч трос, 16 тонна төрле металл әйберләр, шулай ук 2.000 пар аяк киеме; күп кенә электромоторлар һәм башка материаллар бар. Районда акча һәм әйберләр туплау дәвам итә.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕК БУЕНЧА ФРОНТ АЙЛЫГЫ

Яхшы орлык—югары уңыш ул!

„Барлык чәчүлек орлыкларын—бөртекле, техник культуралар, бәрәңге һәм терлек азыгы культуралары орлыкларын 1943 нче елның 1 нче апреленнән соңга калмыйча тулысынча туплап бетерүне тәэмин итәргә!“

(ССР СОЮЗЫ СОВНАРКОМЫ ҺӘМ ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫ КАРАРЫННАН)

СМОТР

Күктә март кояшы балкый. Түбәләрдәге, агач ботакларындагы карлар көмеш төстә ялтырыйлар. Түбә кыекларына асылынып торган боз кисәкләре көндез брелиант тамчыга әйләнәләр, кич булгач тагын очлаеп туңалар. Түбәләрдә, чыпчыклар чыелдый. Тау башлары ала төскә керә.

Болар бөтенесе дә яз галәмәтләре.

—Яз иртә килер быел, чөнки көз озак килде,—дип сөйләшәләр картлар, — чәчүгә әзерлекне тизрәк төгәлләргә кирәк. Бүген әзерлекне тикшерәләр. Нәтиҗә ничек булыр инде.

Смотр таңнан ук башланды. Комиссия, тимерче алачыгын, машина сараен карап, андагы коралларның һәрбер винтен капшап үткәннән соң, чәчүлек орлыкларның торышын тикшерде. Аннан соң алар ат абзарына килеп чыктылар. Һәр ат күздән кичерелде. Шулай ук кырга чыгарылган ашламаларның саклнышына, өлешенә дә әһәмият бирелде.

—Колхозчыларның гомуми җыелышын чакырырга кирәк,— диде колхоз председателе иптәш Әухәдиев.

Колхозчылар клубка җыелдылар. Иң элек иптәш Әухәдиев аларны смотр нәтиҗәләре белән таныштырды.

—Сабанга чыгарга күп калмады, иптәшләр. Сабанда сайрашыр өчен, ындырда ыңгырашмас өчен безгә язгы чәчүне тулы әзерлек белән каршыларга кирәк. Кулда чәчү мәйданын тулысынча капларлык орлык юк әле. Хәзер дәүләт амбарларыннан чәчүлек биргәнне көтеп ятырга ярамый. Мин уйлыйм, безнең колхозчылар үз җирләре турында кайгыртмый калмаслар

Атлар белән дә мактанып булмый әле. Чәчүгә көчле, көр атлар кирәк. Дәүләт эшенә бәйләнгән атлардан башкаларын иртәгедән ялга куябыз. Салам, урман ташу кебек эшләргә үгезләрне, кысыр сыерларны файдаланырга туры килә. 9 баш мөгезле эре терлекне җигәргә өйрәтергә кирәк.

Председательдән соң бригадирлар һәм колхозчылар сөйләделәр. Алар эштәге кимчелекләрне тәнкыйтьләделәр һәм аларны бетерү өчен конкрет юллар күрсәттеләр. Үз хуҗалыкларындагы запасларыннан колхозга чәчү орлыгы биреп торырга булдылар. Шул көнне үк 60 потлап чәчү орлыгы җыелды. 18 центнер бәрәңге күзәнәге әзерләнде.

Шулай итеп җыелыштагы сүзләр практик эшкә бәйләнеп китте. Колхозчылар эштән соң сөйләшә-сөйләшә өйләренә таралдылар.

— Иртәгә фронттан нинди хәбәрләр килер икән.

—Безнекеләр Вязьмадан соң кайсы каланы алырлар икән.

—Егетләр, безгә дә фронттагыларга яхшы уңыш алу белән җавап бирергә кирәк.

Кич шактый салкынайткан иде. Аяк асты шыгырдап тора. Зәңгәрсу күктә йолдызлар чекерәеп яналар. Суык тәннәрне чытыклый.

—Яз шундый шаян инде ул, әле суытып, әле җылытып үчекләргә ярата.

Г. НӘБИУЛЛИН, И. ГАРИПОВ.

Саба районы, Молотов исемендәге колхоз.

ӘЙЕ, СЕЗДЕР, ИПТӘШ ЕГОРОВ!

КАРГАЛЫ, 25 март. (Телефон буенча). Язгы чәчүгә уңышлы итеп әзерләнү һәм аны кыска срокта үткәрү буенча Каргалы һәм Тат. Ялтан МТС лары үзара социалистик ярыш договоры төзегәннәр иде.

Тат. Ялтан МТС ы договорны үтәү өчен көрәшми. Биредә язгы чәчүгә әзерлек гафу ителмәслек акрын бара. Сыек ягулык ташу эшенә МТС яңа гына кереште әле. Газогенераторлы тракторлар өчен язгы чәчү вакытына кирәкле 780 кубометр шакмак ягулыкның бары 11 кубометры гына әзерләнгән. Ремонтланырга тиешле 70 тракторның 40 гына ремонтланган. Тагылма коралларның күбесе кар астында ята.

Политбүлек начальнигы иптәш Егоровтан, ни өчен соң сездә ремонт акрын бара, дип сорагач, ул:

—Запас частьлар җитешми, тагылма коралларны кую өчен урын юк, алар шуның өчен кар астында калдылар да,—ди.

—Ә бу эшләрне кем эшләргә тиеш соң?

— Бездер инде,—ди Егоров.

Тимерче

Аңа сүз бирделәр. Колхоз правлениесенең утырышы бара торган бүлмәнең бер як почмагында утырган, таза гәүдәле, чал сакаллы Тимербай абзый өстәл янына чыгып басты. Аз сүзле булып чыкты ул. Чын күңелдән әйтелгән тыйнак сүзләрне тыңлаган кеше, «Әйе, хикмәт сүздә генә түгел. Сүз аз булсын, эш күп булсын һәм уңышлы булсын!» дигән нәтиҗә ясарга тиеш иде.

— Язгы чәчүгә әзерлегебезне мактап булмый әле,—диде ул.— Фронттагы батыр сугышчыларыбыз рәхмәт әйтерлек итеп эшлисе бар әле безнең. Минем улым Сәетгәрәй бик ачык әйтеп язган. Сез, әти, югары уңыш алу өчен көчегезне кызганмагыз. Без монда ватаныбыз өчен тормышыбызны кызганмыйбыз. Немец шакшыларны дөмектерәбез! —дигән, Сынатмыйк, туганнар. Без, Әхтәм Әхмәтҗанов белән бергәләп чәчү машиналарын вакытында ремонтлап бетерербез, кичектермәбез. Чәчү орлыкларын да хәзердән үк хәстәрләп куярга кирәк.

Тимербай абзыйның сүзен башкалар да куәтләделәр. Правление утырышында чәчү машиналарын ремонтлау, сбруйларны, арбаларны төзәтеп бетерү сроклары билгеләнде.

Тимерче—колхозда зур көч ул. Тимерченең уңышлы эше күп нәрсәләргә бәйләнгән. Чәчүдә, урып-җыюда, сугу эшләрендә тимерченең оста хезмәте таләп ителә. Бигрәк тә хәзер, ремонт өчен кораллар, запас частьлар җитешмәгән вакытта, тимерче үзенең алачыгындагы хәзинәләрдән мөмкинлекләр табарга, иске частьларны эшкәртә белергә, тимер-томырлардан кирәкле әйберләр ясый белергә, тапкырлык һәм уйлап табучанлык күрсәтергә тиеш. Моны Тимербай абзый бик яхшы аңлый.

Тимербай абзый Вахитовны «Кызыл Октябрь» колхозында бик яхшы беләләр. Бу колхозда 15 ел инде тимерче булып эшли ул. Аңа 58 яшь тулган булса да, ул яшьләр кебек дәртләнеп, бирелеп эшли. Үзенең гадел хезмәте аша фронтка ярдәм итү теләге белән яна. Ул 14 нче елгы сугышта немецларга плен төшеп, 7 ел буенча немец алпавытлары кулында кол булып яшәгән. Шуңа күрә дә ул улы Сәетгәрәйне фронтка озатканда:

— Батыр бул, улым. Үлсәң дә батырларча үл. Пленга төшмә! Немецта плен булуның нәрсә икәнен атаң күрде инде,—дип озаткан.

Тимербай абзый үзенең эшен фронттагы сугышчылар һәм улы Сәетгәрәй тарафыннан рәхмәт алырлык итеп эшләргә тырыша. Ул 11 чәчү машинасын, 54 сабан, 14 тырма, 7 культиватор һәм башка күп кенә машиналарны ремонтлап бетерде инде.

Х. ХӘЙРИ.

Красный бор районы.

Колхозларның орлык фондына

Совет патриотлары взносы

66. **Мәрдәнева З.**—Саба районы, «Кызыл юл» колхозы члены, фронтовик хатыны—18 пот ашлык бирде.

67 **Шакиров И.**—Саба районы, Буденный исемендәге колхоз члены—12 пот ашлык бирде.

68. **Әскәрова**—Саба районы, «Кызыл көрәш» колхозы члены—9 пот ашлык һәм 6 пот бәрәңге бирде.

69. **Хөсәенова**—Саба районы, «Арслан» колхозы члены—24 пот ашлык һәм 24 пот бәрәңге бирде.

70. **Биктимирова С.**—Саба районы, «Якты юл» колхозы члены, фронтовик хатыны—12 пот ашлык бирде.

71. **Исмагыйлов**—Саба районы, Пушкин исемендәге колхоз члены—6 пот ашлык һәм 10 пот бәрәңге бирде.

72. **Закирова**—Саба районы, Пушкин исемендәге колхоз члены—6 пот ашлык һәм 9 пот бәрәңге бирде.

Күрше колхозларга ярдәм

ЧҮПРӘЛЕ, 25 март. **(Телефон буенча).** «Ирек таң» авыл хуҗалыгы артеле членнары үз колхозларын чәчүлек орлык белән тәэмин итү турында кыш башында ук зур хәстәрлек күрделәр. Колхозчылар чәчүлек орлык әзерләүне күптән төгәлләделәр.

Хәзер республикабызда чәчүлек орлык туплау буенча декада үткәрелә. «Ирек таң» колхозы членнары күрше тирәдәге колхозларны да чәчүлек орлык белән тәэмин итү турында зур кагыйртучанлык күрсәтәләр.

Күршедәге «Горняк» колхозына колхоз председателе иптәш Гафуров хуҗалыгындагы запастан 31 пот ашлык, 24 пот бәрәңге бирде. Колхоз членнарыннан Кыям иптәш Әбелханов 18,5 пот ашлык, 25 пот бәрәңге, Ибраһим иптәш Хөсәенов 31 пот бәрәңге, бер центнер ашлык, фронтовик хатыны Гаян иптәш Шакурова 25 пот бәрәңге, 24 килограмм ашлык һәм Абдулла иптәш Мәрданов 56 пот бәрәңге бирделәр.

Завод бакчаларында

Язгы йомшак кар өстеннән ике кеше бара. Берсе җилкәсенә теодолит, икенчесе рейка күтәргән. Алар җир үлчәүчеләр. Завком янындагы бакчачылык комиссиясенең кушуы буенча яңа билгеләнгән җирне планлаштырырга һәм участокларга бүлергә килгәннәр.

Бакчачылык комиссиясенең һәм аның председателе иптәш Шмуклерның эше бик күп хәзер. Эшчеләрнең индивидуаль бакчаларында язгы чәчү кампаниясе узган елга караганда оешканрак төстә үтсен өчен барысын да алдан әзерләргә кирәк.

Заводның һәрбер цехына җир участогы билгеләнде. Бу участок цехтагы аерым кешеләргә бүленеп биреләчәк.

Быел заводта индивидуаль бакчачылык эше белән узган елга караганда ике өлеш артык эшчеләр шөгыльләнәчәкләр. Яңа бакчачыларга иң гади һәм гомуми агрономия кагыйдәләре турында сөйләргә кирәк. Заводта индивидуаль бакчачылыкны пропагандалауга зур әһәмият бирелә. Бакчачылык комиссиясенең активистлары участокны ничек эшкәртергә, ашларга, бәрәңге кисентеләрен ничек әзерләргә һәм сакларга дигән темаларга беседалар үткәрәләр, көл җыярга, инвентарьга вак ремонт ясарга киңәш бирәләр.

Завод поселогында йорт хозяйкалары арасында агрономия буенча берничә лекция уздырылды. Ярдәмче хуҗалыкның агрономы аларга орлык өчен бәрәңге кисентеләрен ничек итеп кисәргә кирәклеген күрсәтте. Завод ишек алдында, күп кенә цехларның стеналарында зур такталарга—бәрәңге кисентесен ничек әзерләү һәм саклау турында язып куелган. Профессор Презент тарафыннан төзелгән «Бәрәңге орлыгының резервлары» дигән брошюраны бакчачылык комиссиясе зур тиражда басып чыгарды.

Заводның ярдәмче хуҗалыгында индивидуаль бакчачылар өчен кәбестә һәм помидор үренделәре үстерелә. Йөзләрчә эшчеләр үзләре бәрәңге кисентеләре, ашламалар әзерлиләр.

А. ИГОРЕВ.

Матбугат конференциясендә Хэллның белдерүе

ВАШИНГТОН, 22 март. (ТАСС). Дәүләт секретаре Хэлл матбугат конференциясендәге чыгышында Черчилльнең речена югары бәя биргән. Күчәр державалары көнбатышта да, шулай ук Ерак Көнчыгышта да тар-мар ителгәнчегә кадәр һәм һичбер сүзсез капитуляциягә мәҗбүр ителгәнчегә кадәр сугышны алып барырга карар биргәнлекне Черчилльнең аеруча күрсәтеп үтүен, Хэлл канәгатьләнү белән белдергән. Хэллның сүзләренә караганда, җиңүгә ирешкәнчегә кадәр барлык көчләрне берергә кирәклекне һәм берләшкән милләтләрнең озакка сузылган, гаять зур корбаннар һәм мәхрүмлекләр таләп итә торган сугыш алып баруларын аңлаган хәлдә, сугышның күпмегә сузылачагы турында ашыгыч нәтиҗәләр ясаудан сакланырга кирәклекне Черчилльнең аеруча күрсәтүен ул канәгатьләнү белән әйтеп үткән. Сугыштан соңгы политик проблемаларны хәзерге вакытта тикшерүгә карата ничек карыйсыз, дигән сорауга, Хэлл, бу проблемаларны тикшерү күчәр державаларына каршы сугыш алып баруга комачауламаска тиеш, бәлки булышлык итәргә тиеш, дип күрсәткән.

АНГЛИЯ АВИАЦИЯСЕНЕҢ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 24 март. (ТАСС). Англия информация министрлыгының белдерүенчә, 23 нче мартта көндез бомбардировка авиациясе самолетлары Нант (Франция) янындагы Сен Жозев паровоз төзү заводына һөҗүм иткәннәр һәм югалтуларсыз үз базаларына кайтканнар.

Атлантика яры буенда Германиянең зурлыгы ягыннан икенче урында торган су асты көймәләре базасы Сент-Назерга 23 нче мартка каршы төндә ясалган һөҗүмдә 300 гә якын дүртәр моторлы бомбардировщиклар катнашкан.

23 нче мартта кич белән дошман самолетлары Англиянең көньяк-көнбатыш ярына бомбалар ташлаганнар.

ЛОНДОН, 24 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгы хәбәрчесенең Мальта атавыннан хәбәр итүенә караганда, атаудагы истребительләр һәм бомбардировщиклар көндез дә һәм төнлә дә Сицилия атавындагы һәм Италия яр буендагы объектларга һөҗүмнәр ясауны дәвам иттерәләр. 23 нче мартта иртә белән Поццалло районындагы заводка атака ясалган.

Союзниклар авиациясенең Рабаулга зур һөҗүме

ЛОНДОН, 24 март. (ТАСС). Союзникларның Тын океанның көньяк-көнбатыш өлешендәге берләшкән командованиесе штабының хәбәр итүенә караганда, союзникларның авыр бомбардировщиклары Рабаул портындагы (Яңа Британия атавы) Япония хәрби объектларына төнлә һөҗүм иткәннәр. Самолетлар 54 тонна бомба ташлаганнар. Бомбага тоту нәтиҗәсендә бик күп җимерелүләр булган. Булган мәгълүматларга караганда, японнарның портта тора торган 250 самолетыннан күбесе зарарланган яки юк ителгән.

ТУНИСТА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 24 март. (ТАСС). Союзникларның Төньяк Африкадагы көчләре штабының белдерүендә әйтелгәнчә, кичә, 23 нче мартта көн буе Марет районында бик каты сугышлар дәвам иткән. 8 нче армия дошманның барлык контратакаларын уңышлы рәвештә кире кайтарган, дошманның җанлы көчләренә һәм техникасына зур югалтулар китергән. Пленныйларның саны 2.000 кешедән арткан.

Гафса районында Эль-Гаттардан көнчыгыштарак Америка гаскәрләре дошманның көньяк-көнчыгыштан ясаган атакаларын кире кайтарганнар һәм үз позицияләрен саклап торалар.

Макнассидан төньяктарак союзниклар гаскәрләре бераз алга киткәннәр, ләкин дошманның көчле каршылыгына очрыйлар.

Ш. Х. САДЫЙКОВ

21 нче мартта хезмәт бурычларын үтәгән вакытта ТАССР Верховный Советы депутаты, ватаныбызның турылыклы улы Шаһи Хатип улы Садыйков һәлак булды.

Иптәш Садыйков үзенең бөтен гомерен Совет ватанына хезмәт итүгә бирде. Ул үзенең соңгы сулышына кадәр сайлаучылар алдында биргән вәгъдәләрен намус белән үтәде.

Иптәш Шаһи Хатип улы Садыйков 1908 нче елда Әлки районының Карга авылында ярлы крестьян семьясында туа. 1920—1925 нче елларда, авыл мәктәбен тәмам иткәннән соң, ул шул ук авылда батрак булып эшли. Аннары, комсомол оешмасы ярдәме белән, ул Спас педагогия техникумына, аннан соң Казан хәрби мәктәбенә укырга керә. Хәрби мәктәпне тәмамлаганнан соң иптәш Садыйков хәрби оешмаларда һәм партия оешмаларында эшли.

Иптәш Садыйков 1926 нчы елдан башлап Ленин комсомолы члены, 1930 нчы елдан башлап Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) Партиясе члены.

Иптәш Садыйков нинди генә постта булса да, партия һәм хөкүмәт аңа нинди генә эшне тапшырса да, ул һәрвакыт гаять зур энтузиазм белән, арыны-талуны белмичә эшли, ватан өчен ныклык белән үз-үзен аямыйча хезмәт итә. Иптәш Садыйков ватаныбызның батыр һәм гайрәтле улы, Ленин—Сталин партиясенә, халкыбызга бөтенләй бирелгән кеше иде. Иптәш Садыйковның хезмәтләрен илебез, аны Кызыл Байрак ордены белән бүләкләп, билгеләде. Безнең сугышчан дустыбыз, татар халкының турылыклы улы иптәш Садыйков турындагы якты истәлек безнең йөрәкләребездә һәрвакыт сакланыр.

Динмөхәметов, Гафиятуллин, Гафаров, Шәмсиева, Дулов, Чурсин, Юдин, Щербаков, Прокушев, Миңлегалиев, Әхмәдуллин, Контюков.

КРОСС ЙОМГАКЛАРЫ

Кызыл Армиянең 25 еллыгы исемендәге профсоюз - комсомол кроссын үткәрү буенча республика күләмендәге оештыру комитеты шушы көннәрдә кросска йомгак ясады. Кроссда барлыгы 147.338 кеше катнашты. Оештыру комитеты Казан шәһәренең Бауман, Молотов һәм Ленин районнарында, Мамадыш һәм Бөгелмә районнарында, Зеленодольск шәһәрендә кросска әзерлек һәм аны үткәрүнең яхшы үткәнлеген күрсәтте.

Республика күләмендәге оештыру комитетының карары буенча, ВЛКСМ Өлкә Комитетының һәм ТАССР Совнаркомы янындагы физкультура-спорт эшләре комитетының күчмә Кызыл Байрагы кроссда беренче урынны алган Бауман районына тапшырылды (ВЛКСМ райкомы секретаре иптәш Лебедева). Кроссда икенче урынны алган Ленин һәм Бөгелмә районнарына, өченче урынны алган Зеленодольск шәһәренә һәм Молотов районына, 4 нче урынны алган Мамадыш районына ВЛКСМ Өлкә Комитетының һәм физкультура-спорт эшләре комитетының грамоталары бирелде.

БЕЛДЕРҮ

Марксизм-ленинизм кичке университетының партия тарихы, халыкара мөнәсәбәтләр, экономика һәм философия бүлекләренә укучылар кабул ителә. Урта белеме булган барлык кешеләргә керергә мөмкин. Уку срогы 6 айдан 1 елга кадәр. Гаризалар 1 нче апрельгә кадәр кабул ителә. Адрес: Бауман урамы, 62.

КИНО

„СТАЛИНГРАД“

(ДОКУМЕНТАЛЬ ФИЛЬМ. РЕЖИССЕР ВАРЛАМОВ МОНТАЖЫ).

Художникның хыялы, детальләрне, гомуми тәэсирне көчәйтү өчен кулланыла торган катлаулы алымнар бу картинада юк. Андагы көчле сәнгать—бөек тарихи вакыйгаларның шаһите булучылыкта. «Сталинград» картинасы үзенең садәлеге һәм бөеклеге белән, анда күрсәтелгән чын хакыйкатьнең бөеклеге белән тамашачыны таңга калдыра.

19 нчы елгы Царицынны хәтерләрендә саклап калган һәрбер кеше, фильмның беренче кадрларын күрү белән үк, тирән соклана: безнең Сталинградыбыз нинди матур шәһәр булып үскән! Зур, ак йортлар, атаклы заводларның искиткеч зур корпуслары, бакчалар, киң һәм чиста урамнар...

Ләкин бирегә дошман якынлашып килә. Шәһәр куркыныч хәлдә дип игълан ителә. Сталинград тирәләрендә йөз иллә мең кеше ныгытмалар төзүдә эшлиләр. Дошман авиациясенең беренче һөҗүмнәре. Матур йортларны төтен һәм ялкын кочып ала. Күктә фашист козгыннар кара болыт булып очып йөри. Совет зенитчылары аларның күбесен атып төшерә. Ләкин дошман көчле әле. Гитлер үз авиациясенең барлык көчен шушы бер шәһәр өстенә ташларга карар биргән... Урамнар, кварталлар җимерелә, таш һәм тузан өеменә әверелә. Йорт-җирсез калган шәһәр халкы, әйберләрен, төенчекләрен күтәреп, яшеренер урыннарга баралар. Менә бер музыкант ватылган контрабасын күтәреп бара. Менә, уенчыкларын яки икмәк кисәген күкрәкләренә кысып, яшь балалар атлыйлар.

Ләкин совет кешесенең рухы көчле. Дошманның һичбер нинди җимерүләре дә, кан коюы да, котырынган үлем уты да Сталинградлыларның каршы тору сәләтләрен сындыра алмый. Сталинградка килү юлларында безнең көчле резервларыбыз туплана. Немецлар, инде тагын да бер тапкыр басым ясау белән шәһәрне алабыз, дип уйлаганда гына, Верховный Баш Командующий иптәш Сталин җитәкчелегендә әзерләнгән көчле көчләребез хәрәкәткә килә. Совет артиллериясенең җимергеч уты дошман өстенә дәһшәтле үлем булып ява башлый. Данлыклы Кызыл гаскәрләр һөҗүмгә күчәләр.

Дошманны чолгап алган боҗраның һаман кысыла баруын, Дон һәм Көньяк-Көнбатыш фронтлары сугышчыларының бергә кушылып, кочаклашып үбешүләрен тамашачылар тирән дулкынлану белән карыйлар. Бу кыска моментларны озынайтасы, тагын, тагын карыйсы килә. Ләкин вакыт көтми. Немец генераллары совет командованиесенең ультиматумын кире кагалар. Тынлык. Хәлиткеч, генеральный һөҗүм башлануга 5 минут вакыт калган. Менә, тарихта тиңдәше булмаган бу һөҗүм башлана. Орудиеләрнең залплары, шартлаулар, снаряд ялкыннары... Боҗра һаман һаман кысыла бара.

Фильмда, Сталинград янындагы сугышларда култа төшерелгән немец кино-хроникасыннан алып кертелгән кызыклы урыннар бар. Берлинның зур мәйданнарыннан берсендә—ялтыравык каскалы, сайланып алынган, масайган немец гаскәрләре парадта горур рәвештә маршировать итәләр. Һәм менә шуның артыннан ук—аларның хәзерге хәлләре, Сталинград янындагы кыяфәтләре: туңган бөрешкән, аякларына салам чорнаган, чабата кигән, сәләмә солдатлар, куркак күзләрен ялтыратып, безнең конвой астында чак-чак атлыйлар. Немец солдатларының үле гәүдәләре Сталинград далаларын каплаган. Менә аларның талап алган һәм юлда ташлап калдырган иске-москылары...

Совет командованиесенә пленга бирелгән ун меңнәрчә немец офицерлары һәм алар арасында—генерал-фельдмаршал Паулюс. Алар барысы да,—кайчандыр ялтыравык каскалары, механизмлы курчакларча бик тигез атлаулары белән горурланган бу юлбасарлар,—«бөек Германия» хакына бетерү, талау, үтерү теләге белән безнең илебезгә басып кергәннәр, Сталинградка килгәннәр. Ә менә хәзер Сталинград аларны уйланырга өйрәтте.

Сталинград картинасы—ватан сугышы тарихының, фашистлар планнарының һәлак булуы тарихының һәм совет көралы даны тарихының гаять бөек документы ул. Тау-ташлар чыдый алмыйча ватылган, җимерелгән урыннарда рус кешесенең, совет кешесенең куәте, җиңүгә булган ышанычы һәм омтылышы җимерелмәслек нык булып чыкты. Сталинградлыларның рухын һичбер нинди көч какшата алмады.

Сталинград эпопеясына багышлап бик күп һәм гүзәл художестволы картиналар тудырылыр, ләкин аларның берсе дә бу документаль булган «Сталинград» кебек көчле тәэсирле була алмас. Каты садәлеге, реаль сугыш күренешләрен чагылдыруы, тирән дулкынландыручан хакыйкатьне күрсәтүе белән үзенә аерым урын тоткан бу картина—безнең бөек сынауларыбыз һәм үз-үзебезне аямыйча көрәшеп җиңүгә ирешүебез турында сөйләүче объектив шаһит ул.

Сталинград картинасы өчен Сталин исемендәге премия бирелү белән, аны тудыручы коллективның кино сәнгате өлкәсендәге героик һәм гүзәл эшләренә тулысынча лаеклы бәя бирелде.

А. ДУБИНСКАЯ.

Җаваплы редактор **И. ҮЗБЕКОВ.**

ТЕАТРЛАРДА ҺӘМ КИНОЛАРДА

Татар дәүләт опера һәм балет театры. Бүген — **«Башмагым»**.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры 27 нче мартта—**«Эрджикинез»**.

Зур драма театры. Бүген — **«Нашествие»**.

Яшь тамашачылар театры. Бүген —көндезге 1 сәгатьтә һәм кичке 7 сәгатьтә — **«Москвичка»**.

Дәүләт циркы. Бүген 3 бүлектә **зур цирк тамашасы**. Кич 8 сәгатьтә башлана.

Татарстан дәүләт филармониясе. Бүген Менжинский исемендәге клубта **комедияләр кичәсе**. Кич 8 сәгать 30 минутта башлана.

«Электро» яңа документаль фильм — **«Сталинград»**. «Унион» көндез һәм кич — **«Моряк кызы»**. «Пионер» көндез **«Руслан һәм Людмила»** һәм **«Боксерлар»**, кич **«Минем мәхәббәтем»**. «Чаткы» көндез — **«Әкиятләр»** һәм **«Чапаев»**, кич — **«Фронтка концерт»**.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—73—27, Редактор урынбасары АТС 76—29, секретариат һәм авыл хуҗалыгы бүлеге 79—29, промышленность, транспорт, партия тормышы һәм хатлар бүлекләре 78—93, типография 36—60.

ПФ1087 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФ ИЯСЕ № Заказ 542